Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Иске Үзи авыл җирлеге башкарма
комитеты
423050, Татарстан Республикасы
Аксубай районы, Иске Үзи авылы,
Ленин ур., 2А нче йорт
т. 4-13-48

Исполнительный комитет
Староузеевского сельского поселения
Аксубаевского муниципального района
Республики Татарстан
423050, Республика Татарстан
Аксубаевский район с.Старое Узеево,
ул.Ленина, д.2А
т. 4-13-48

КАРАРЫ

№ 5 18 октябрь 2022 ел

" Аксубай муниципаль районының
Иске Үзи авыл җирлеге
Иске Үзи авылында халык җыенын билгеләү
һәм гражданнарның үзара салым чараларын
кертү һәм файдалану турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы «Иске Үзи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 1. 2022 елның 27 октябрендә 14 сәгать 00 минутка Иске Үзи авылы мәдәният йорты бинасындаТатарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлегенең Иске Үзи авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча түбәндәге адрес белән: ТР, Аксубай районы, Иске Үзи авылы, Ленин урамы, 2а йорт, гражданнар җыены үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2023 елда Аксубай муниципаль районының Иске Үзи авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә : 1 группа инвалидлардан, БВС ветераннарыннан һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Украинада катнашучы гранданнарның гаиләләреннән тыш ; җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчалардан түбәндәге эшләрне башкаруга ризамы::

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- юл полотносын урнаштыру (грунт күтәрү, урамнарны ком һәм вак таш белән яңарту)

- щебень сатып алу;

- трактор өчен запас частьләр һәм асылмалы җиһазлар сатып алу .

2. Җирлек халкының массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерүне оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буйларына иркеле үтеп керүен тәэмин итү:

- Иске Үзи авылы мәдәният йорты территориясендә балалар уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру

3. Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итү Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:

- Иске Үзи авылында су башнясын монтажлау шартнамәсе буенча товарлар, материаллар сатып алу һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү

ӘЙЕ ЮК

4. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының Иске Үзи авыл җирлегенең информацион стендларында һәм Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән кабул ителгән көннән 10 көн эчендә игълан итәргә http://aksubaevo.tatar.ru.

Аксубай муниципаль районы
Иске Үзи авыл җирлеге башлыгы: Н.В.Айдова